Кукмара муниципаль районы

Каенсар авыл җирлеге Башкарма комитеты

# КАРАР

2020 елның 8 апреле № 8

Каенсар авыл җирлегенең Салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибен раслау турында 2020 елда

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^3$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Каенсар авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Каенсар авыл җирлегенең Салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүнең кушып бирелә торган Тәртибен расларга.

2. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә 1 сентябрьгә кадәр муниципаль берәмлек башкарма комитетына хисап елы өчен, хисап елына кадәрге ел өчен белешмәләр җибәрергә тәкъдим итәргә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Каенсар авыл җирлегенең һәр салым чыгымы буенча Каенсар авыл җирлеге бюджетының керми калган керемнәре суммасы турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кукмара муниципаль районы
Каенсар авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе И.А.Мифтахов